<table>
<tr>
<td>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙ-<br>ОНЫ ӘТӘС АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘК-<br>ЧЕСЕ<br>423737, Әтәс авылы,<br>Үзәк урам,<br>75 а йорты. Тел.5-90-25</td>
<td></td>
<td>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>РУКОВОДИТЕЛЬ АТЯСЕВСКО-<br>ГО СЕЛЬСКОГО ИСПОЛНИ-<br>ТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКТА-<br>НЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНО-<br>ГО РАЙОНА<br>423737, село Атясево,<br>ул. Центральная, дом 75 а,<br>Тел. 5-90-25</td>
</tr>
</table>

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

26 июнь 2025 ел №14

"Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе турында" 16.03.2020 ел 9 нче номерлы Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Актаныш районы прокуроры вазыйфаларын башкаручының 2025 елның 18 июнендәге 02-08-02-2025/Прдп 203-25-20920005 номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Әтәс авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе турында» 16.03.2020 ел, 9 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. Тәртипнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Аналитик белешмә кергән, адресланган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең, электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьләрнең саны, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре, шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнарның саны, гражданнарны шәхсән кабул итү һәм шәхси кучмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында мәгълүматны (булган очракта) үз эченә ала.»

2. Әлеге карарны " Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга/

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әтәс авыл башкарма комитеты җитәкчесе: Г.М.Ганиева